СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2023 г. Агрыз № 30-2

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 22.10.2020 елның 2-2 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«Балигъ булмаганнар эшләре һәм Татарстан Республикасында аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2020 елның 22 октябрендәге 2-2 номерлы карарына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 22.10.2020 елның 2-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 15.12.2022 елның 23-3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).
4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары И.И. Ямалиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Советының
29.08.2023 елның 30-2 номерлы
карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 22.10.2020 елның 2-2 номерлы карарына үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү турында» 22.10.2020 елның 2-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы**

1. Җәметова Гөлнас Фелисовна - **комиссия рәисе,** Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;
2. Сәфиуллина Вәсилә Гарәфетдиновна - **комиссия рәисе урынбасары,** «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
3. Зарипова Альмира Тахировна – **комиссия рәисе урынбасары,** Әгерҗе районындагы Татарстан Республикасы МТ һәм СЗ социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);
4. Хакимова Эльвира Рәисовна - **комиссиянең җаваплы секретаре,** Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы мөдире;

**Комиссия әгъзалары**:

5. Сутягина Альмира Расилевна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы баш белгече;
6. Богданова Зарина Ренатовна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторының әйдәүче белгече;
7. Гарифуллин Илшат Илнурович - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге башлыгы;
8. Сергеева Татьяна Сергеевна – Балаларның һәм яшьләрнең гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең «Татарстан Республикасы Беренче Әгерҗе муниципаль районы хәрәкәте» җирле бүлекчәсе рәисе;
9. Яппарова Лилия Дуфаровна- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ярдәмчесе;

10. Затулина Наталья Сергеевна- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының ППМС хезмәте педагог-психологы;

11. Мөхәммәтҗанов Рифат Рафинатович – бүлек башлыгы урынбасары - Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча полиция башлыгы (килешү буенча);

12. Петряева Елена Анатольевна - Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенең ОДН өлкән инспекторы (килешү буенча);

13. Караяни Виталий Дмитриевич - «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ психиатр-наркологы (килешү буенча);

14. Мифтахова Ксения Сергеевна - «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ район педиатры (килешү буенча);

15. Шайдуллин Айрат Разакович – Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең Әгерҗе муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлекчәсе башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы (килешү буенча).».